ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

03.10.2025 г. № 1293

Гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керəменең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының минималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керeменең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен 56 781,23 сум итеп билгеләргә;

2. Гражданнар һәм алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары милкендәге мөлкәтнең яисә салым салынырга тиешле ялгыз яшәүче граждан хакын билгеләргә:

2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 2 720 160,00 сум;

2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 5 440 338,36 сум;

2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 8 160 480,00 сум;

2.4. Дүрт кешелек гаилә өчен – 10 880 640,00 сум;

2.5. Биш кешелек гаилә өчен – 13 600 800,00 сум;

2.6. Алты кешелек гаилә өчен – 16 320 960,00 сум;

2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 19 041 120,00 сум;

2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 21 761 280,00 сум;

2.9. Тугыз кешедән торган гаилә өчен – 24 481 440,00 сум;

2.10. Ун кешедән торган гаилә өчен – 27 201 600,00 сум.

3. «Гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керeменең һәм алар белән бергә салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакының

максималь күләмен билгеләү турында» 2024 елның 27 сентябрендәге 1002 номерлы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкченең Беренче урынбасары Р.М. Латыйпов